Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАРЫ

2023 елның 09 октябрендәге №165

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 № 136-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2006 елның 04 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексы, 2006 елның 03 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексы, 2003 елның 06.10 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (2022 елның 14 июлендәге редакция) "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" РФ Хөкүмәтенең 09.06.2006 № 363 карары, "Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында" 2006 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге хакында" 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының 2023 елның 15 сентябрендәге “Кама Тамагы авыл җирлегеннән файдалану кагыйдәләре” гавами рәвештә тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре белән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча кушымтада бирелгән Кагыйдәләрен (https://fgistp.economy.gov.ru/) расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында дәүләт теркәвенә алганнан соң (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Советы рәисе Н.А. Вазыйхов